**Республика Татарстан**
**Кукморский муниципальный район**
**СОВЕТ КОШКИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**Татарстан Республикасы**
**Кукмара муниципаль районы**
**КҮКШЕЛ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422115, Татарстан Республикасы, Кукмара районы,
Күкшел авылы, Театр урамы, 38 йорт
телефон: (84364) 31-2-35
эл. почта: Kosh.Kuk@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Күкшел авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**12 гыйнвар, 2024 ел** **№2**

**«Кукмара муниципаль районы Кукшел авыл җирлегенең Кукшел авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 27.10.2023 ел, №1 Кукшел авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районы Кукшел авыл җирлегенең Кукшел авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Күкшел авыл җирлеге Уставына, Күкшел авыл җирлеге Советы

Карар кабул итте:

1. 2024 елның 26 гыйнварында 14 сәгать 00 минутка гражданнар Җыенының беренче этабын, 2024 елның 26 гыйнварында 16 сәгать 00 минутка җыенның икенче этабын билгеләргә. «Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Күкшел авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 27.10.2023 ел, №1 Күкшел авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Күкшел авылы, Театр урамы, 41 адресы буенча СДК бинасында гражданнар җыенын уздырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлегенең Күкшел авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 27.10.2023 ел, №1 Күкшел авылына гражданнар җыены карарына гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча түбәндәге үзгәрешләр кертүгә ризамы:
2 нче пунктта:

а) беренче абзацта «963 сум» сүзен «1000 сум» сүзләре белән алыштырырга

б) түбәндәге эчтәлектәге яңа абзацлар белән тулыландырырга:

су белән тәэмин итү системаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, проект-смета документациясе;

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Күкшел авыл җирлеге уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Җирлек башлыгы Р. Р. Хәмидуллин